**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Советы**

**Карар № 93**

Таш-Чишмә авылы 01 октябрь 2024 ел

**Милеккә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексынын 32 булеге, “Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында” 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, прокуратураның 2024 елның 28 июнендәге №02-08-02-2024/Прдп295 номерлы протесты нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге территорясендә мәҗбүри түләнергә тиешле физик затлар милкенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2.1. 0,1% нисбәттә:

- Әлеге Карарның 2.4 пунктчасында күрсәтелгән, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарына;
- Һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмаларына;

2.2. 0,2 % нисбәттә:

- фатирлар, фатирларның өлешләренә;
- бүлмәләргә;

2.3. 0,3 % нисбәттә:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләренә;

- әгәр мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларына;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга;

2.4. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар күчеш чорына 1,2% һәм 2028 елдан башлап гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 2%;

2.4.1. Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2025 елда 1,2% һәм 2026 елдан башлап 2,5% ;

2.5. Салым салуның башка объектларына карата 0,5%.

3. Салым ташламалары Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясында һәм әлеге карарның 3.1 – 3.3 пунктларында билгеләнгән дип билгеләргә;

3.1. Салым ташламасы ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы йортта фатирга милек хокукына ия физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр күләмендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булган очракта, ташлама суммасы уртак милектә катнашучы һәркем өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча арта алмый.

3.2. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителәләр:

3.2.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

3.2.2. әлеге Карарның 3.2.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары;

3.3. Әлеге карарның 3.2 пункты белән билгеләнгән салым ташламасы салым түләүче сайлавы буенча гаиләгә туры килә торган бер салым объектына (фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә, торак йорт яки торак йортның бер өлеше) карата бирелә. Салым ташламасы Өҗем авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 79 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарын, 03.06.2015 № 108, 19.10.2015 № 4, 02.07.2018 № 70, 09.03.2019 №87, 22.04.2019 № 90, 03.10.2019 № 103 карарлары редакциясендә үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.